ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2020 Олы Кайбыч ав. № 136

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 30 апрелендәге 222 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу турында» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә алу» муниципаль хезмәт күрсәтүенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 21 февралендәге 269/20 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 30 апрелендәге 222 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм алу турында» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2. пунктның 15 абзацын төшереп калдырырга;

16,14 абзацларны 14,15 абзацлар дип санарга;

1.2. пунктының 13 пунктчасындагы «наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшереп тору органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.6. пунктының икенче абзацындагы «комплектлаганда Системадагы балаларның яше агымдагы елның 1 сентябренә исәпләнә» җөмләсен төшереп калдырырга;

3.4.6. пунктының 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Буш урыннар булганда белем бирү Оешмасына кабул итү бөтен календарь ел дәвамында гамәлгә ашырыла»;

II бүлектәге «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» таблицасында 2.8. пунктның 2 графасында «- теләгән Оешмада тәрбия һәм укытуны алып бару теленең теләгәнгә туры килмәве» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә:

2.1. Әлеге карарны муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренә җиткерергә;

2.2. «Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) исәпкә кую һәм алу» муниципаль хезмәт күрсәтүеннән файдаланучылар булган гражданнарга мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуни-кация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республика-сының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Биккуловага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров